**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы «Шланга авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Шланга авылында гражданнар җыены КАРАРЫ**

**3 нче декабрь 2019 ел Шланга авылы №1**

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы “Шланга авыл җирлеге " муниципаль берәмлеге Шланга авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге Уставының 12.1 статьясы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге Советының 2019 елның 10 октябрендәге 44/1 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында»гы нигезләмә, 2019 елның 3 декабрендә тавыш бирү йомгаклары турында, 2019 елның 3 декабрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында хисап комиссиясе беркетмәсе нигезендә:

Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә, тавыш бирү тәмамланган вакытта, җыенда катнашучы 536 кеше кертелгән, гражданнар җыенында катнашучыларның тавыш бирүдә катнашкан саны-348, бу исемлеккә кертелгән гражданнарның 64,93 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан 348 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде, бу гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучыларның 98,28% ын тәшкил итә; «Каршы» позициясе өчен, җыенда катнашучы 6 кеше тавыш бирде, бу 1,72% тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә карар иттеләр:

1. 2019 елның 3 декабрендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Шланга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Шланга авылында гражданнар җыенын 2019 елның 3 декабрендә уздырылган, гражданнар җыены нәтиҗәләре-дөрес дип танырга.

2."Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Шланга авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Шланга авылында су белән тәэмин итүне проектлаштыру;

- Киров, Ленин, Совет, Тукай, Комсомол, К. Маркс урамнарындагы юлларның бер өлешенә вак таш салу белән килешәсезме?" дигән мәсьәлә буенча карар кабул дип танырга.

3. 2020 елда Чүпрәле муниципаль районының Шланга авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә.

- Шланга авылында су белән тәэмин итүне проектлаштыру;

- Киров, Ленин, Совет, Тукай, Комсомольская, К. Маркс урамнарындагы юлларның бер өлешенә вак таш салу.

4. Халык җыены нәтиҗәләрен «Туган як " газетасында бастырырга, шулай ук Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Шланга авыл җирлегенең Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районынын Шланга авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль

Шланга авыл җирлеге башлыгы,

халык җыенында рәислек итүче: А.А. Мөхәррәмов